| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | 11.03.2025<br>483 | **КАРАР** |

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» 2024 елның 25 сентябрендәге 1465 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 2 июлендәге 546 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында 2025 елга азык-төлек продуктларына чыгымнарны өстәмә индексацияләү турында» 2025 елның 7 февралендәге 5600-МР номерлы карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» 2024 елның 25 сентябрендәге 1465 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында азык-төлек продуктларына чыгымнар нормативы:

| Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының | Туклану продуктларына чыгымнар нормативы, көнгә сум/тәрбияләнүче | |
|---|---|---|
| | гомумүстерешле (шул исәптән төрле яшьтәге) төркемнәр | санатор төркемнәр |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| атналык эш сәгате саны | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән алып белем бирү мөнәсәбәтләре туктатылганга кадәр | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән алып белем бирү мөнәсәбәтләре туктатылганга кадәр |
|---|---|---|---|---|
| 3-4 | 33,88 | 42,65 | | |
| 5-6 | 81,28 | 102,39 | | |
| 7-12 | 135,49 | 170,64 | 175,78 | 234,39 |
| 24 | 169,34 | 210,66 | 219,73 | 289,36 |

2. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларын әлеге карарның 1 пункты белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларын финанслау нормативлары нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 4DF13A255AE51927759AA463F36F11E0
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 09.01.2025 до 04.04.2026

Э.Р. Әхмәдиева